**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Зур Сукаеш авылы № 9 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2017 елның 31августындагы 12 номерлы карары белән расланган, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен белешмәләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 30 мартындагы 4 номерлы карар редакциясендә)

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Указы , Азнакай шәһәр прокуратурасының 2022 елның 10 мартындагы 02-08-02/2022 номерлы протесты нигезендә

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2017 елның 31августындагы 12_номерлы карары белән расланган, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен белешмәләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 30 мартындагы 4 номерлы карар редакциясендә) 3 пукнтның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы (мондый алыш-бирешнең суммасы) хезмәткәрнең (эшченең) һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының

рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.http://pravo.tatarstan.ruhttp://aznakayevo.tatar.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис Закирова З.Җ.